**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

2020 елның 10 феврале Базарлы Матак авылы 47№

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 маенда кабул ителгән 237 номерлы «Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның муниципаль функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябредәге 131 - ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге 294 -ФЗ номерлы "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" Федераль закон, Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 маенда кабул ителгән 237 номерлы «Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның муниципаль функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» (2009 елның 14 маендагы 185 А номерлы редакция)карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның муниципаль функциясен үтәүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 кисәк 2.4 пункт 2.4.1.2.пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

2.4.1.2. Торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан, Дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган әлеге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау турында белдерү нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаганнан бирле;";

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo ktatarstan .ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: И. В. Йосыпов